СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

29 март, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 35 (8047) | Бәясе билгеләнгәнчә

# 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

## Норлатта православие чиркәве ачылды

***Кичә, 28 мартта Норлатта яңа төзелгән Илья чиркәвен ачу тантанасы булды. Күмәк һәм аерым иганәчеләр средстволарына салынган бу гыйбадәт йортының төзелеше район һәм шәһәр җитәкчелегенең даими игътибар үзәгендә булды һәм аларның зур ярдәме белән барды.***

***Бу тантаналы вакыйгага Норлаттан һәм авыллардан йөзләрчә кеше җыелды, читтән дә мәртәбәле кунаклар килде. Яңа ачылган чиркәүдә беренче гыйбадәт укылды һәм шулай итеп православие динен олылаучы, аның изге кануннарын кабул кылучы һәркемгә гыйбадәт йортының ишекләре ачык.***

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**





*Матбугат - 97*

## «Дуслык»ка льготалы язылу!

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

1 апрельдән элемтә бүлекләренә килеп, матбугат басмаларына язылганда без Сезнең иң беренче бланкларны «Дуслык»ка дип тутырачагыгызга шикләнмибез. Шунысын да әйтик, редакция, район элемтә узелы белән килешеп, район газетасына ярты елга язылу бәясен элеккечә, ягъни 23.400 сум көенә калдырды. Бу хакта үзегез күргән - белгәннәрнең моңарчы безнең газетаны алдырмаганнарына да җиткерерсез дип уйлыйбыз.

### Һәм, иң мөһиме!

**Апрельнең 1еннән 10сына кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына льготалы бәягә, ягъни 16.200 сумга гына язылып калырга мөмкин.**

**Атнасына өч көн чыга торган матбугат органына язылуның шуннан да арзанрак бәясенең әле беркайда да булганы юк. Шулай булгач, нибары 16.200 сум акчагызны кызганмыйча, район газетасына язылып куйсагыз, ел ахырына кадәр райондагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышандырабыз.**

**Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!**

## ИМАНЛЫ БУЫН ҮСТЕРӘБЕЗ

«Нәүрүз бәйрәме быел уздырылырмы икән?», «Яз тиз килергә җыена, Нәүрүз бәйрәмен күрмичә калырбызмы инде?».

Бу сорауларны өлкәннәрдән дә, мәктәп укучыларыннан да еш ишетергә туры килде. Шулай булмый ни, менә икенче ел инде Бикүле урта мәктәбендә Нәүрүз бәйрәме бик оешкан төстә уздырыла. Һәм халыкның 400 ел буена онытылып торган Нәүрүз бәйрәмен оештыру өлеше быел да алдан ук башланды. Ә 21 март көнне укулар тәмамлануга, мәктәп ишек алды, аллы - гөлле чәчәкләрне хәтерләткәндәй, бәйрәмчә киенгән укучылар һәм укытучылар, үзләренең балаларын һәм бәйрәмдә катнашучы һәрбер кешене котлау өчен килгән ата - аналарның шатлыклы авазлары, дугаларына кыңгыраулар таккан, чиккән сөлгеләр бәйләп, һәртөрле шарлар белән бизәлгән җигүле атлар белән тулды. Һәр класс укучылары Нәүрүзбикә - бәйрәмнең хуҗасы - килгән вакытка сый - нигъмәтләрдән сыгылып торган өстәлләр әзерләп куйдылар. Килгән кунакларны һәм укучыларны Гөлсирә апалары Камалова, Тәнзилә Әһлетдинова, Нурсинә Садыйкова кебек аш - су осталары кайнар коймак белән сыйлап тордылар. Ә нинди бәйрәм ди инде ул җырсыз - шигырьсез? Һәрбер укучы үзенең сәләтен күрсәтеп калырга тырышты. Күмәк җырлау, шигырьләр сөйләү «Нәүрүз» сүзенә тарихи белешмә бирүләр дә булды бәйрәмдә. Нәүрүзбикәнең килүен һәр кеше дә түземсезләнеп көтте. Бик тә гүзәл, сылу, озын толымлы, ягымлы карашлы татар кызы булып күз алдына килә бит ул Нәүрүзбикә. XI сыйныф укучысы Гөлназ Рәхмәтуллина нәкъ менә шушы гүзәллек сыйфатларына ия дә инде. Яз чәчәге сыман елмаеп - балкып, милли киемнәргә киенеп бәйрәм белән котларга килгән Нәүрүзбикәдән күзләрне алып булмый, гаять сокландыргыч иде. Нәүрүзбикә укучыларны һәм укытучыларны бәйрәм белән котлады, бәйрәмгә чакырылган - лаеклы ялда булган өлкән укытучылары Суфия апа Камалетдинова һәм Разия апа Әһлетдиноваларга бүләкләрен тапшырды.

Ә кыңгыраулы, чиккән сөлгеләр белән бизәлгән атларда утырып йөрүләре ни тора? Әнә, ирле - хатынлы Габделхәй һәм Рәшидә Латыйповалар, Васыйл Гыйльфанов кебек ата - аналар укучы сабыйларының шатлыкларын икеләтә арттырганнар бит!!! Эштә булуга карамастан, төш вакытында ял итим әле диеп тормаганнар, атларын бизәп, укучыларны урам әйләндерергә махсус килгәннәр. Бу көнне һәрбер кеше бер - берсенә саулык - иминлек, кырларга мул уңыш, мал - туарының үрчем булуын теләде.

Бәйрәм кичкә кадәр музыка астында дәвам итте. Талчыккан, арыган булсалар да, шатлыклы елмаюлары йөзләреннән китмәгән сабыйларга, күтәренке күңелле өлкән яшьтәге кешеләргә карап мин уйга талдым. Явыз Иван карарыннан изелгән, юкка чыгарылырга тиешле булган халкым 400 ел буена яшәп килгән әзәрлекләүләрдән котылып бара кебек. Онытылган бәйрәмнәр, гореф - гадәтләр халкыма кире кайтарыла. Бигрәк тә яшь буын моны тоеп үсә. Мәктәптән кайтып баручы укучының азан тавышын ишетеп, туктап, дога кылуы куанычлы хәл түгел мени?! Димәк, әле безнең рухи тамырыбыз корымаган, иманыбыз яши. Яшь буын аңлап, иманлы булып үсә. Заманында өч мәхәлләле булган, золым җилләре баш очында уйнаган вакытта да мәчетле, иманлы калган Бикүле халкы, авылы, иманым камил, үзенең гореф - гадәтен аяк астына салып таптамас, ата - бабаларыбыз нигезенә кызыллык китермәс, нәсел тамырын корытмас. Амин!

Шушы бәйрәмне оештырган һәм укучыларны чын татар - милли гадәтләргә тәрбияләүгә бөтен көчен куйган мәктәпнең директоры Г.Г.Камалов, аның урынбасарлары Р.В.Әхмәтшина - Шакирова һәм Н.Г.Вәлиевага укучыларның гына түгел, барлык бикүлеләрнең дә рәхмәте зур иде.

**Зөлфия ГАЛИУЛЛИНА,**
**рус теле һәм әдәбияты укытучысы.**

## Кайда күпме сөт савалар?

**Саннарның беренче баганасы - район хуҗалыкларында быелның 27 мартында бер сыердан савылган сөт, икенчесе- узган елның шул көнендәгедән артык яки ким (килограммнарда).**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Дуслык» | 21,8 | + 8,0 | Синдряков исем. | 8,5 | + 1,5 |
| «Кондырча» | 16,8 | + 7,4 | «Татарстан» | 8,3 | + 1,6 |
| Мичурин исем. | 15,0 | + 5,0 | Кузнецов исем. | 8,0 | + 1,8 |
| «Восход» | 12,3 | + 8,6 | «40 лет Победы» | 7,8 | + 2,4 |
| «Сөлчә» | 12,3 | + 3,1 | «Мамык» | 7,7 | + 3,1 |
| Якты Күл | 11,0 | + 5,1 | «Үрнәк» | 7,4 | + 1,1 |
| «Рассвет» | 11,0 | + 2,9 | «Заря» | 7,3 | + 3,6 |
| «Чишмә» | 10,6 | + 4,0 | МСО | 6,8 | + 1,3 |
| «Чирмешән» | 10,4 | + 2,4 | Әлмәт | 6,5 | + 0,8 |
| Хафизов исем. | 10,0 | + 1,3 | «Игенче» | 6,3 | + 1,7 |
| «Төрнәс» | 9,9 | + 3,9 | «Правда» | 5,6 | + 1,4 |
| «Родина» | 9,8 | + 1,7 | «Комбайн» | 5,5 | + 1,7 |
| «Заветы Ильича» | 9,7 | + 2,5 | «Таң» | 5,5 | + 0,1 |
| М.Җәлил исем. | 9,0 | + 1,8 | «Алга» | 5,3 | + 1,3 |
| Киекле | 8,5 | + 3,1 | | | |
| «Москва» | 8,5 | + 2,3 | **Район буенча** | **9,2** | **+ 2,7** |

## Декларация тутырдыгызмы әле?

Октябрь районы буенча Дәүләт салым инспекциясе 31 мартта гражданнарның үз керемнәре турында декларация тапшыруының соңгы көне икәнлеген искәртә.

27 мартка 300 физик, эшмәкәрлек белән шөгыльләнүдән керем алучы 128 зат, төп эш урыныннан тыш та керем чыганагы булган 102 кеше декларация тутырды инде.

**Бүген, 29 мартта салым инспекциясе иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр эшли. Декларация тапшырырга ашыгыгыз!**

## *Җәйге вакытка күчәбез*

**30 марттан 26 октябрьгә кадәр җәйге вакытка күчәбез. Русиядәге барлык сәгать телләре 30 мартта төнге сәгать 2дә бер сәгатькә алга күчерелә.**

## Кеше һәм аның эше

# НӘСЕЛДӘН ҮК ИГЕНЧЕ ШУЛ УЛ



Тумышы белән Әлки районының Иске Чаллы авылыннан ул. Гомерлек крестьян нәселеннән. Профессиясе буенча агроном, җир йөзендә иң кыйммәтле нәрсә булган икмәк үстерүче.

...Һәммәбезнең дә бала чагы - чуклы сөлге кебек: ялгыш кына бер җебен тартып җибәрдең исә, бер - бер артлы бүтәннәре сүтелә башлый. Хатирәләр дә шулай. Кираметдинның хәтер йомгагы вакыйгаларга бай. Барысын да ачык хәтерли ул. Урак өстенең элекке сихрилеген дә, тузанлы юлларда яланаяк йөргән чагын да. Ә иң истә калганы - иртән мәктәпкә җыенганда (укырга 17 чакрымдагы Алпарга йөрделәр) әнисенең мичтән кабартма алганда өйгә башны әйләндерердәй булып таралган ипи исен дә...

Ипи исе. Анысы Кираметдинның гомер кыйбласын билгеле. Табынга әти - әниләре белән бергә алты бала да утыра торган ишле крестьян гаиләсендә үскән Кираметдин кешенең тормышында җирне кадерләү һәм шуның әҗере итеп анда икмәк үстереп алудан да мөһимрәк нәрсә юклыгына бик иртә төшенә... Шуңа күрә дә менә рәттән өч дистә елдан артык инде аның бар уе җирнең уңдырышлылыгын күтәрү турында. Шуңа күрә ул чаакта, 58 дә мәктәпне бетергәч тә кем булу, тормышта нинди юл сайлау турында баш ватасы булмый аңа. Чөнки үз юлын әллә кайчан сайлап куйган була инде ул. Әтисе, бабасы юлын. Ә инде тумыштан килгән үҗәтлеге, мөстәкыйль нәтиҗәләр ясарга омтылуы, хезмәт сөючәнлеге һәм үз һөнәре буенча мөмкин кадәр күбрәк белергә тырышуы аңа Казан авыл хуҗалыгы институтында укыганда бик нык булышлык итә. 1963 елда Кираметдин Әхмәтсәгыйровны Октябрь районына эшкә җибәрәләр. Районда гына түгел, республикада да күз уңындагы хуҗалыкларның берсе «Дружба»да баш агроном булып эшли башлый. Һәм таләпчән, шул ук вакытта бик игелекле рәис Шәриф Сәгыйрович Хафизов кул астында аның командасында ун ел буе эшли ул, иң ныклы буыннарның берсе була.

- Әйтегез әле, ул елларда эшләргә авыр булдымы?

- Җиңел түгел иде. Җире биш мең гектар чамасы булган колхозда эшләүнең нәрсә икәнлеген чамалау кыен түгел. Эшкә бөтен көчне куярга туры килде. Техника артык күп түгел, ә кул хезмәте, киресенчә, җитәрлек иде. Бер чөгендер генә дә ни тора иде бит. Колхоз җитештерү - тәҗрибә хуҗалыклары исемлегендә булгач, без һич тә кеше рәтендә генә эшләп кала алмый идек. Кыскасы, эш муеннан булды. Касыйм Измайлович Идрисовның бик күп ярдәмен күрдем мин - баш зоотехник белән тыгыз бәйләнештә эшләдек без.

- Район авыл хуҗалыгы идарәсенә Сезне 73 нче елда күчерделәрме?

- Ул чакта Хафизовның бер дә җибәрәсе килмәгән иде. Хәер, үзем дә җилкәмә шундый авыр йөк алырга бер дә атлыгып тормадым. Ни әйтсәң дә, монда бит бер генә хуҗалык өчен җавап бирәсең, ә анда дистәләрчә колхоз - совхозны кайгыртырга кирәк...

Авыл хуҗалыгы идарәсенең баш агрономы булып Әхмәтсәгыйров 1989 елга кадәр эшли. Үзендә булган өметне тулысы белән аклый. Аңа һәрвакытта да төпле фикер йөртү, эшен төгәл белү хас була. Агрономнарны бодай, шикәр чөгендере һәм кукуруздан мул уңыш алу, продукциянең үзкыйммәтен киметү серләренә, авыл хуҗалыгы культураларын игүнең иң алдынгы технологияләренә өйрәтә. Чәчү мәйданнарының структурасын камилләштерү, яңа сортлар табыштырып аларны районда кулланылышка кертү юнәлешендә күп эшли. Һәр ике төр - органик һәм минераль ашламалар белән дөрес эш итүләрен таләп итә. Кул астындагылардан сорый белә. Чөнки аның үзеннән дә эш таләп итәләр.

- Кираметдин Әхмәтсәгыйрович, сезнеңчә, агроном нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

- Бу турыда бик кыска гына итеп тә әйтергә мөмкин. Үз эшеңне яратырга кирәк, аны ваклыкларына кадәр белү шарт. Һәр яңалыкны кулланырга омтылу мөһим - бер урында таптанып әллә кая китә алмыйсың. Һәм тагын... Җирдә игенчеләр, механизаторлар эшли, агрономның төп булышчылары шулар, аларны онытырга ярамый. Ә иң мөһиме, эш өчен яна белергә кирәк, җир битарафларны һич тә өнәми.

Менә җиде ел инде Кираметдин Әхмәтсәгыйрович НГДУның «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгында эшли. Ул мондада үзенең шул принципларыннан тайпылмый: ару - талуны белмичә эшләп, кырларның уңдырышлылыгын күтәрә барырга! Нәтиҗәләрнең иң яхшысына ирешергә! Ирешелгәннәр белән тынычланмаска!

Агроном Әхмәтсәгыйровны белгән бар кеше аның эш сөючәнлегенә, җыйнаклыгына һәм көче ташып торуга шакката.

- Әхмәт ташландык бер бригада иде, кулдан - кулга да күп йөрде. Ни рәтле мастерской һәм складлар, ни җылы гараж юк иде авылда. Ә кешеләре әйбәт, эшчән, техниканы эшләтә дә, саклый да беләләр. Шуңа да алар белән уртак телне тиз таптык без,- ди Кираметдин Әхмәтсәгыйрович. - Иң элек солыча баскан басуларны рәткә кертергә тотындык. Шикәр чөгендере уңышын җыеп алуны тулысынча механикалаштыру эшенә алындык. Игенчелекнең төп нигезе булган чәчүлек материал әзерләүгә зур игътибар бирәбез...

Ярдәмче хуҗалыкның җыйнак кына җирендә төрледән - төрле культуралар игәләр. Терлекчелекне азык белән тәэмин итү бурычы да уңышлы хәл ителә һәм анысы үзләренеке үзләренә җитә - читтән сатып алганнары юк. Май заводына да чимал бирәләр. Орлыкның да мөмкин булганын үзләре өчен үзләре әзерлиләр. Шулай булгач, агроном Әхмәтсәгыйров үзенең монда эшләгән еллары да нәтиҗәле булды дип санарга хаклы. Былтыр әнә бер гектардан уртача 42,5 центнер ашлык җыеп алдылар - районда бер күрсәткеч!

Кырлар әле кар астыннан чыгарга гына азаплана. Тик яз - яз инде ул,- чәчү җиткәнен сизми дә калуың бар. Әмма биредә бу көнгә алдан ук ныклап әзерләнделәр. Көз - кыш кырларга 5 мең тонна чамасы органика чыгарылды, минераль ашламаны да шактый ук туплап куеп, кирәк кадәрен көздән туңга сөргәндә кертеп калдырдылар. Әхмәтсәгыйров кайсы кырда нәрсә үстерәчәкләрен күңелдән белә иде: әнә теге басуда бодай, монысында солы чәчеләчәк... Тик менә уҗым кырларын гына бозып кабаттан чәчәргә туры килмәгәе - көздән бер дә рәтләп яңгыр булмады бит...

... Аннан инде урагы да озак көттермәс һәм игенченең тагын бер сынау сәгате сугар. Ә агроном Әхмәтсәгыйров өчен ул сәгатьләрнең барысы да сынау сәгате һәм аның әлегә сынауларда сынатканы юк. Буразнада тәгәрәп үскән, нәселдән үк игенче бит ул.

**Т.НАЗАРОВА.**

## Ветераннар колагына

***Татарстан хөкүмәтеннән 1996 елның декабрендә кабул иткән 1030нчы номерлы Карарының исеме бик озын булса да, асылы «Хезмәт ветераны» исеме алу өчен документлар җыю тәртибен билгеләүдән гыйбарәт. Һәм район хакимиятенең социаль яклау службасы мартта документлар кабул итә башлады. Баштан 7 көндә үк 400ләп кеше учетка куелды. Шулай да бу эшнең тәртибе белән кызыксынучылар бихисап әле, безгә дә шул хакта мөрәҗәгать итүчеләр күп. Шул уңайдан без социаль яклау бүлегеннән бу хакта җентекле аңлатып бирүләрен үтендек. Анда аңлатуларынча,***

# АШЫКМАГЫЗ - ӨЛГЕРӘСЕЗ ӘЛЕ

«Хезмәт ветераны» исеме бирү өчен картлык буенча һәм тиешле ел эшләгәннән соң пенсиягә хокук бирүче, ягъни эш стажы турында документлар (хезмәт кенәгәсе яки белешмә), шулай ук СССР, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре турындагы документлар (медаль, мактаулы исем таныклыклары, орден кенәгәсе) нигез булып тора. Болардан тыш, гариза һәм 3 х 4 см. зурлыктагы бер фоторәсем дә тапшырырга кирәк.

Шәһәрдәгеләр хакимиятнең социаль яклау бүлегендә учетка басалар. Ә авылда? Авылда торучыларның документларын җирле үзидарә Советларында җыеп, 7 көн эчендә шушы бүлеккә китерергә тиешләр. Бу эш әле соңрак башкарылачак.

«Хезмәт ветераны» исеме бирү турында Указга Татарстан Республикасы Президенты кул куя, ә таныклыклар социаль яклау бүлегендә һәм җирле үзидарә органнарында тапшырылачаклар.

Инструкциягә «Хезмәт ветераны» исеме бирүгә нигез булып тора торган хөкүмәт бүләкләре исемлеге дә теркәлгән. Болар: Герой исеме, Россия Федерациясенең 8 ордены, 17 медале, дистәләрчә мактаулы исемнәре, СССР орденнары һәм медальләре дә санап кителә. Бу исемлектә «Хезмәт ветераны» медале, 1941 - 1945 елгы Бөек Ватан сугышында Җиңү хөрмәтенә чыгарылган юбилей медальләре, «1941 - 1945 елгы Бөек Ватан сугышы чорында намуслы хезмәт өчен» медале, күп балалы аналарга бирелә торган бүләкләр дә бар. «Хезмәт ветераны» исемен алу хокукы Татарстан Республикасының ТАССР Верховный Советының Мактау грамоталарын алган, республикабызда бирелә торган Почетлы исемнәргә ия кешеләргә дә бирелә. Кыскасы, районда бу исемне дәгъваларга хаклы кешеләр байтак. Күпләргә бу исем икенче мәртәбә биреләчәк - 1989 елга кадәр «Хезмәт ветераны» медале белән бүләкләү бар иде бит.

Социаль яклау бүлегендә документлар тапшыруда бик үк кабаланмаска киңәш итәләр. Югыйсә, бүлеккә көн саен йөзләрчә кеше килә һәм, билгеле инде, озак көтәргә мәҗбүр булалар. Барлык ветераннарның да документларын кабул итәчәкләр, аларны карау вакыты да чикләнмәгән.

**Һәм соңгысы. Федераль Законда ветераннарга коммуналь һәм башка кайбер хезмәтләр өчен түләүләрдә ташламалар каралган. Әмма алар пенсиягә чыкканнарга гына кагыла. Дөрес, бу җәһәттән республика органнарыннан әлегә бернинди дә документ - мазар килгәне юк. Көтәләр.**

**Т.НАЗАРОВА.**

# Спортчылар хәзерли

Әлмәт физкультура техникумын тәмамлагач туган авылы Түбән Норлатка кайтты ул һәм әле берничә ел элек кенә үзе белем алган мәктәбендә балаларга физкультура укыта башлады. Безнең коллектив та аны колач җәеп каршы алды, аңа зур өметләр багъланды.

Егет биредә эшли башлавының беренче елында ук үзен яхшы педагог, оста оештыручы, сәләтле спортчы итеп танытты. Көн - төн белән санашмыйча эшләде ул. Тәүлекнең байтак вакытын спорт залында үткәрде егет. Раил спортның милли төре - көрәшне аеруча үз итте. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар»,- дип нәкъ менә Раил кебекләр турында әйтәләрдер, мөгаен. Ул да тырыша һәм, бер вакытта да үз дигәненә ирешмичә калмый. Безнең Түбән Норлат урта мәктәбе егетләренең районда гына түгел, берничә тапкыр республика күләмендә дә милли көрәш буенча чемпион исемнәрен яулаулары, укучыларыбызның спортчы даны үсүе шул хакта сөйли.

Раил үз осталыгын камилләштерү белән дә даими шөгыльләнә. Төрле ярышларда, сабантуйларда катнашып, призлы урыннар яулады инде ул. Бүләккә алынган кыйммәтле сервизлар, суыткычлар һәм башка призлар алып әнисе Рәисә апаны күпме сөендерде ул.

Раил гаиләдә булдыклы, акыллы ир. Хатыны Гүзәл белән дә тату яшиләр алар.

Гомумән, Р.Рәхмәтуллин киләчәктә дә коллективыбыз маягы булып, спорт буенча авылыбызның данын күтәрер дип ышанасы килә.

**Ф.ӘХМӘДИЕВА,**
**укытучы.**

## Исемнәрен урамнарга бирделәр

# Мулланур Вахитов урамы



Мулланур Муллажанович Вахитов 1885 нче елның 22 августында Пермь өлкәсенең Көнгер районы Казаево авылында туа. 1899 нчы елда Казандагы реаль училищега укырга керә. Бередә әдәбиятны өйрәнү буенча «Шимбә» түгәрәге оештыра, РСДРПның Казан комитетының идея йогынтысы астында булган марксистик әдәбият өйрәнү буенча яшерен түгәрәккә йөри.

Училище тәмамлагач, Петербург техник институтының экономик факультетына укырга керә, соңраксәяси ышанычсызлык аркасында аннан куыла.

1911 нче елда ул - психоневрология институты студенты. Ул бередә студентлар һәм предприятиеләр эшчеләре арасында яшерен революцион эш алып бара.

1917 нче елның апрелендә Мөселман социалистик комитетын оештыра, 1 нче Май демонстрациясендә актив катнаша. Соңрак «Кызыл Байрак» гәзите мөхәррире була. Кызыл Армиянең Казан отряды белән Казанда Совет власте урнаштыру өчен кораллы восстаниедә катнаша. 1917 елда беренче ревком әгъзасы итеп сайлана.

В.И.Ленин Вахитовның революцион, интернациональ эшчәнлеген югары бәяли.

1918 нче елның гыйнварenda Милләтләр эшләре буенча халык комиссариатының үзәк мөселман хәрби комиссариаты комиссары һәм хәрби эш буенча халык комиссариаты каршындагы үзәк мөселман коллегиясе рәисе итеп билгеләнә, Кызыл Армиянең мөселман частьләре формированиеләре белән җитәкчелек итә. Үзәк газеталарда Россия мөселманнарына мөрәҗәгать белән чыгып, аларны революцияне яклаучылар сафына басарга өнди.

1918 нче елда ул Идел буе районнарына азык - төлек буенча комиссар итеп билгеләнә. В.И.Ленин мандаты буенча азык - төлек хәзерләү һәм Казан губернасы районнарына озату буенча бөтен чараларны да күрә.

1918 нче елның августында М.Вахитов Казанны Чехословакия корпусының революциягә каршы частьләре һәм ак гвардиячеләрдән саклап, 2 нче татар - башкорт батальоны составында көрәшә. 17 нче августта кулга алына һәм атып үтерелә.

Республикада Вахитов истәлегенә берничә предприятие, хуҗалыклар һәм урамнарга аның исеме бирелде.

**Рубриканы И.САНДЛЕР алып бара.**

## Газета газета укучы

## ИШЕК ТЫШЫНДА ИШЕК...

*Фикер*

Янгынның кешегә нинди зыян, кайгы китерүе барыбызга да мәгълүм. Әмма безнең уебызча районда янгыннарны кисәтү буенча профилактик эшләр йомшак алып барыла. Кайсы гына йортка керсәң дә, баскыч мәйданчыкларындагы тәртипсезлекләргә юлыгасың. Сандык, төрле тартмалар тора анда. Алай гына да түгел, кайбер акыллы башлар үз ишек төпләрен капиталь стена белән бүлеп тә алалар. Ә янгын чыга калса, әйбер дә чыгара алмыйсың, өстәвенә, бу янгын сүндерүчеләр өчен дә өстәмә мәшәкать тудыра бит. Адәм баласы бу турыда кайгы килмәгәндә уйлап та карамый.

Хәер, тар ишекләр, кысан коридорлар үлем - китем вакытында мәетне чыгарырга да комачаулый.

Безнең Карл Маркс проспектындагы 7 нче һәм 5 нче йортларда да шундый ук хәл. «Үзешчән» фатир хуҗаларына әйтеп тә караганыбыз бар, әмма алар безнең сүзне санга да сукмыйлар. Ә бит янгын хезмәте яисә башка хезмәтләр тарафыннан аларның берсе генә булса да катгый кисәтелсә, бу башбаштаклыкка чик куелыр иде.

**Абдуллина, Малярова, Мостафина, Коннова һәм башкалар.**

## Чыбыкчалар әзерләр вакыт

Дачасында карлыган утыртмаган кеше сирәктер. Бакчачылар аны салкынга чыдамлылыгы өчен дә, уңышны тиз һәм мул биргәнгә күрә дә үз, якын күрәләр. Ә «С» витаминына байлыгы ягыннан карлыган җир җиләге һәм алманы узып китеп, бары гөлҗимештән генә калыша. Тик карлыганның эре җиләкле кыйммәтле сортларын табу кыенрак. Шуңа да «Мичурин истәлеге» «Память Мичурина» дигән сортлы карлыган яз утыртыласы чыбыкчаларын мартта ук әзерләп куям мин. Аларны төптән үк кисеп алам. Чыбыкчаларның буе 15 - 18 сантиметр, юанлыгы 0,5 сантиметр була. Кискәндә бөредән бер сантиметр калдырып кыеклап кисәм. Чыбыкчаларны салам белән каплап карга күмеп куям. Иртә язда, җирдә туң 20 сантиметрга кадәр эрегәч чыбыкчаларны 1 - 2 бөрене өстә калдырып 45 градус авышлыкта туфракка кадап чыгам. Рәтләрне төньяктан көньякка таба ясыйм, чөнки алай иткәндә алар яхшырак җылына. Карлыганның уңышы биш елга кадәр әйбәт була - куак картайган саен уңышы да азая баруына үз тәҗрибәмдә инандым. Безнең бакчада 70 төп карлыган бар һәм уңышлы елда шулардан 18 - 20 чиләк карлыган җыеп алабыз. Куакларны даими яңартып торырга кирәклеген үз тәҗрибәмдә беләм.

**В.КОМОЛОВ.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Тормыш иптәшем, әтиебез **Рөстәм Зәки улы Сәфәргалиевны** 3 апрельдә булачак туган көне белән тәбрик итәбез. Аңа шатлык, бәхет, нык сәламәтлек телибез.

Гомерне бит еллар билгеләми,
Яшәү дәрте булсын күңелеңдә,
Барыбызга канат, терәк булып,
Армый атла гомереӊ үренә.
**Тормыш иптәшең, балаларың.**






*Район мәдәният йортында бары бер генә көн - 3 апрельдә 10, 14, 19.30 сәгатьләрдә гаять зур «Каскад» шоу - группасы.*

***Программада: маймыллар, тавыклар, этләр, питоннар һәм аю. Шулай ук цирк артистлары: жонглерлар, акробатлар, фокусчылар, клоуннар, пластика. Соңыннан билетлар буенча лотерея уйнатыла, хайваннар белән фотога төшеп була.***

Тел.: 2 - 16 - 55.

## Акцияләр сатып алабыз:

## *«Газпром» РАҖ,*

**«Сургутнефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл» НК АҖ,**
**«Татнефть» АҖ,**
**«Ноябрьскнефтегаз» АҖ,**
**«Юганскнефтегаз» АҖ,**
**«Пурнефтегаз» АҖ,**
**«ЕЭС России» РАҖ**
**акцияләрен сатып алабыз.**

***Бәяләр - иң кыйммәте.***

Адрес: Совет ур., 94, тел.: 2 - 23 - 10, 2 - 18 - 61, (эш көннәрендә иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр). ТР финанс министрлыгыннан бирелгән 72 нче номерлы лицензия.

## *Пассажир һәм йөк ташучылар игътибарына!*

**«Дәүләтара ташу белән шөгыльләнүче транспорт чаралары экипажлары эшчәнлегенә кагылышлы Европа килешүе» (ЕСТР) Халыкара Шартнамәсе нигезендә (ә Россия Федерациясе аңа керә) һәм «Автотранспорт белән дәүләтара һәм шәһәрара пассажирлар һәм йөкләр ташуның иминлеген күтәрү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1996 ел, 3 августта чыккан 992 нче Карарын үтәп, 1997 елның икенче яртысыннан автобусларга һәм йөк автомобильләрен тахографлар белән мәҗбүри җиһазлау кертелә. Тахограф - автомобильнең хәрәкәт тизлеген, узган юлын, үткән вакытны, шоферның эш һәм ял вакытларын, башка техник параметрларны теркәп баручы прибор.**

**Белеп тору өчен шуны хәбәр итәбез: Татарстан территориясендә тахограф кую буенча сертификатка ия мастерскойлар Яр Чаллыда бар: чикләнгән җаваплылыклы «Риат» җәмгыяте (җитәкчесе Владимир Васильевич Пономарев, тел.: 56 - 03 - 99) һәм чикләнгән җаваплылыклы «АССЛтд» җәмгыяте (җитәкчесе Владимир Александрович Корнеев, тел.: 53 - 03 - 10).**

Дәүләт транспорт инспекциясенең Кама арьягы бүлеге.




## Могҗиза

- Без ирем белән аның хосусый өендә яши идек,- дип сөйли Пермь шәһәреннән Евгения Усталова. - Һәм үземне һәрвакыт сәеррәк хәлдә сизә идем. 1969 елның декабрендә - мин 27 яшьләрдә идем ул чакта - гаҗәеп бер хәл булды.

Мунча көне иде. Мин мунчага соңгы кеше булып юынырга кердем. Бераз кер дә юып алырга иде исәбем. Таз белән килгән идем, көтмәгәндә... башыма ком коелмасынмы! Ярар, үзем юынып алыйм дип, чүмеч белән кайнар су багына тыгылдым. Ә анда - боз. Башымны сабынлап, юарга итәм. Бакта боз кебек салкын су. Югыйсә, мунчада эссе, мич кайнар.

Килеп кергәч, ирем дә гаҗәпләнде моңа. Мин, юына алмыйм, дип елап утырам. Ирем кулын бакка тыгып карады да, суның салкынлыгын тоеп сүгенде.

Мин мунчадан рәтләп юынмаган хәлдә чыктым. Кайнанам миңа: «Сине фәрештәләр саклаган, ә бит бала тапканнан соң алты атна ялгыз гына мунча керергә ярамый»,- диде.

## Мунчада аерылышу

Воронежда гаиләләр мунчада таркала башлады. Ул болай була: ирләр төркем - төркем мунча керергә ярата. Мунчада аракы эчәләр, ашыйлар. Шулай да хатын - кызларсыз әлләни кызык тоелмый. Акрынлап саунага кызларны чакыралар... бер иргә бер кыз туры килә.

Ял итүче бер ир чакырылган «кызлар» арасыннан үз хатынын танып ала. Алар арасында җәнҗал чыга. Эссе саунада тагын да кызурак булып китә. Вакыйга әлеге ир һәм хатынның аерылышуы белән тәмамлана.

## *Менә бу рекорд, ичмасам*

67 яшьлек американлы Вирлинд Рэдмон бик тә сәер рекорд куйган: үз гомерендә аны исерек хәлдә машина йөрткәне өчен 390 тапкыр кулга алалар. Шул исәптән 100 тапкырында штраф түли, 33 тапкырында шоферлык таныклыгын алалар, 5 тапкырында калган гомерендә яңадан руль артына утыру хокукыннан мәхрүм итәләр.

## *Бирәнлек нәселдән килә*

Күп тонналы йөк машинасы йөртүче инглиз Питер Даудесвилл, иң тиз һәм күп ашаучы буларак, Гиннес рекордлар китабына кертелерлек рекорд куйган. Моңа ирешү өчен ул 2 секундта 1,2 литр сөт эчкән, 12,2 секундта 91 метр спагетти ашаган, 107 секундта әрчелгән 17 банан, 7 минутта 113 пирожный ашаган. Хатыны һәм ике улы әлегә күп ашау белән генә мактана ала. Димәк, бирәнлек гаиләгә нәселдән килә.

## Кем ераграк төкерә

Көнбагыш орлыгын 6,93 метрга төкереп, Француз Филипп Кайо төкерү ярышында чемпион булды. Дөрес, ул ватандашы узган ел куйган рекордка (10,28 м.) җитә алмады. Ләкин моңа җилнең каршы булуы комачаулаган булса кирәк.

**(«Мәдәни җомга»дан).**

## *Сатабыз*

**Пушкин поселогында йорт нигезе салынган йорт. Вариантлар да булырга мөмкин.** Тел.: 2 - 11 - 34.

***

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21061.** Тел.: 2 - 11 - 55.

***

**Чистарту корылмалары тирәсендә гараж.** Адрес: Совет ур., 185 - 17.

***

**Совет ур., 189 йортында 1 бүлмәле, 35 кв. метрлы фатир.** Тел.: 5 - 17 - 09 (кичке 5тән соң).

***

**1984 елгы ВАЗ - 2105 (кузовы 1993 елгы ВАЗ - 2107-неке, кыйммәт түгел).** Тел.: 5 - 25 - 64 (кичке 4тән соң).

## *Сатабыз яки алмаштырабыз*

**Ашыгыч төстә бик әйбәт хәлдәге УАЗ - 469, кыйммәт түгел, яки ВАЗга алмаштырыла.** Тел.: 2 - 10 - 68.

***

**Киекле ак он һәм фураж тегермәне сатыла. Сүтеп алырга мөмкин. Түләү төрлечә.** Тел.: 5 - 25 - 76, 3 - 31 - 75.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, җомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2083 данә. Заказ N 6032.